ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.04.2021 г. Заинск № 200

**"Балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында" 2020 елның 31 мартындагы 141 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында" 2020 елның 31 мартындагы 141 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлеге:

а) балигъ булмаганның гаризасы (1 нче кушымта);
б) балигъ булмаган затның ата-анасының икесенең дә яисә башка законлы вәкилләрнең гариза-ризалыгы (2 нче кушымта);
в) балигъ булмаганның паспорт күчермәсе (төп нөсхәне күрсәтеп);
г) ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) шәхесен раслый торган документлар (төп нөсхәләр һәм күчермәләр);
д) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсе;
граждан хәле актларын теркәү органнары яки Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;
е) мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча гаилә әгъзалары буларак гаризада күрсәтелгән затлар арасында туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы башка документларны (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.) бирә ала;
ж) хезмәт эшчәнлеге турында документлар (хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә кәгазь чыганактагы хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, тиешле рәвештә таныкланган, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (ул эш бирүче янында булса) электрон документ рәвешендә), индивидуаль эшкуар буларак теркәлү турында таныклык;
з) ата-ананың берсен ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү) турында, аны хокукый сәләтсез дип тану турында суд карары күчермәсе (күрсәтелгән хәлләр булганда);
2. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.
3. Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:
а) шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);
б) почта аша.
4. Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.
1.2. Административ регламентның 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:
а) «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булу-булмавын яки булмавын раслый торган белешмәләр һәм башка документлар формаларын һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының

булуын яки булмавын раслый торган белешмә һәм башка документларны тутыру кагыйдәләрен раслау турында" 2018 елның 01 октябрендәге 200 номерлы РФ Юстиция министрлыгы боерыгы белән расланган 2 номерлы форма буенча туу турында белешмә (граждан хәле актларын теркәү органнарыннан);

б) эчке эшләр органнарының эзләнә торган ата-ананың урнашу урыны билгеләнмәгәнлеге турында белешмәсе;

в) шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән балигъ булмаганга карата шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).

г) граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар.

2. Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

а) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы аңа хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны тапшыру һәм мәгълүмат бирү яисә гамәлләр башкару;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыру, моңа 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлар керми;

г) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда, документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, документлар тапшыруны.

1.3 административ регламентның 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарына, төзелмәләр һәм корылмаларга, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан биналарга), ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;

2. тимер юл, һава, су транспорты һәм шәһәр, шәһәр яны, шәһәрара автомобиль транспорты, элемтә һәм мәгълүмат чаралары белән тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар тудыру (транспорт коммуникацияләре аша җәяүлеләр хәрәкәтен җайга сала торган светофорларның һәм

җайланмаларның төсле тавыш сигналлары белән кабатлануын тәэмин итә торган чараларны да кертеп);

3. социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

4. күз күрүе һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларында ярдәм күрсәтү;

5. инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын аларның мөмкинлекләре чикләнүне исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

6. инвалидлар өчен кирәкле аваз һәм күз белән күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләр һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-ноктала шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене аның белән бергә кертүне рөхсәт итү;

7. махсус укытылган булуынраслый торган, тиешле форма буенча бирелгән һәм дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, халыкны социаль яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгели торган документы булганда социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына инвалидны озатып йөрүче этне кертү;

8. халыкка хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә инвалидларга ярдәм күрсәтү.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

И.П.Фәттахова
7 12 31
Юрист